СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 июнь 2026 ел. г.Мензелинск № 1

# Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының 23.08.2017 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә капиталь ремонтка, модернизацияләүгә, реконструкцияләүгә мохтаҗ булган, Минзәлә муниципаль районы муниципаль хосусыйлыгындагы бинаны, корылманы, муниципаль милек корылмасын алга таба эксплуатацияләү өчен яраксыз һәм сүтелергә тиеш, эксплуатацияләү өчен яраклы дип тану тәртибе турында» № 3 карарына үзгәрешләр кертү турында

Үзгәрешләрнең 3 нче пункты нигезендә, 2019 елның 21 августындагы 1082 номерлы «Россия Федерациясенең субъектлары территориясендә урнашкан гражданнарның торак биналарына зыян китергән очракта, үз теләге белән страховкалау механизмын кулланып, зыянны кире кайтару программасы рамкасында кире кайтарырга тиешле зыян микъдарын билгеләү ысуллары, торак бинасына китерелгән зыянны экспертиза үткәрү кагыйдәләрен, бюджет системасы бюджет чаралары исәбеннән бирелә торган ярдәм һәм страховка түләү исәбеннән, үз теләге белән страховкалау механизмын кулланып, Россия Федерациясенең субъектлары территориясендә урнашкан гражданнарның торак биналары зыян китергән очракта, зыянны кире кайтару программасы рамкасында кире кайтарырга тиешле зыянны билгеләү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган, торак бинасын яшәү өчен торак итеп тану, торакны яшәргә яраксыз, күпфатирлы йортны аварияле һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт итеп һәм торак йортны бакча йорты итеп тану турындагы Нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр, муниципаль норматив-хокукый актларны канунннарга тәңгәл китерү максаты белән, Минзәлә муниципаль районы Советы карар КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының 23.08.2017 «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә капиталь ремонтка, модернизацияләүгә, реконструкцияләүгә мохтаҗ булган, Минзәлә муниципаль районы муниципаль хосусыйлыгындагы бинаны, корылманы, муниципаль милек корылмасын алга таба эксплуатацияләү өчен яраксыз һәм сүтелергә тиеш,

эксплуатацияләү өчен яраклы дип тану тәртибе турында» № 3 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Крарарның 4 нче пунктында «инфраструктура үсеше һәм инвестицияләр буенча В.Р.Гыйләҗетдинов» сүзләрен «Дмитрий Александрович Чухланцев» сүзләренә алыштырырга;

1.2. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бинасын, төзелешен, муниципаль милек корылмасын алга таба эксплуатацияләү өчен яраксыз һәм сүтелергә тиеш, эксплуатацияләү өчен яраклы, РТ Минзәлә муниципаль районы территориясендә капиталь ремонтка, модернизацияләүгә, реконструкцияләүгә мохтаҗ дип тану турында» 2 нче Кушымтадагы 4 бүлекнең 4.5 пунктының 3 абзацында «яки дәүләт контроль-күзәтчелеге уздырырга вәкаләтле орган яки органның нәтиҗәсе» сүзләрен «, яки дәүләт күзәтчелеге (контроле) органының яки торакны тикшерү экспертизасының нәтиҗәсе, ул «Торакны яшәү өчен торак итеп тану, торакны яшәргә яраксыз дип тану, күпфатирлы йортны аварияле һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын торак йорты итеп һәм торак йортын бакча йорты итеп тану тәртибе турында» 28.01.2006 № 47 карары белән расланган РФ Хөкүмәтенең 28.01.2006 № 47 карарының 42 нче пункты белән билгеләнгән», сүзләренә алыштырырга;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Дмитрий Александрович Чухланцевка йөкләргә.

Совет рәисе А. Ф. Сәлахов